**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

_______________　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ ________

**Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы «Актаныш муниципаль районы гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 12 сентябрендәге ПР-155 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган су объектларында гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасына 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү турында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 16 октябрендәге 935 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган су объектларында гражданнарның оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү өчен кулланыла торган вазыйфаи окладларның күләмнәрен расларга.

| № т/б | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Оешма җитәкчесе | 7724,0 |
| 2. | Оператив дежур | 7028,0 |

2. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 12 сентябре, ПР-155

нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" гы 2020 елның 27 декабре, ПР-244 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И.Габдулхаев